ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ
ЕЛАБУЖСКОГО
МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
АЛАБУГА МУНИЦИПАЛЬ
РАЙОНЫ БАШКАРМА
КОМИТЕТЫ

ПОСТАНОВЛЕНИЕ 28.08.2025 1437 КАРАР

Татарстан Республикасы Алабуга муниципаль районы Башкарма комитетының «Административ хокук бозулар турында беркетмәләр төзергә вәкаләтле вазифаи затлар хакында» 2016 елның 21 гыйнварындагы 91 карарына үзгәрешләр кертү турында

«Татарстан Республикасының аерым закон актларына балигъ булмаганнарга автомобиль бензинын сатуны чикләүне билгеләү өлешендә үзгәрешләр кертү турында» 2025 елның 23 июлендәге 53-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законын үтәү йөзеннән, Татарстан Республикасы Алабуга муниципаль районы Башкарма комитеты

КАРАР БИРӘ:

1. Татарстан Республикасы Алабуга муниципаль районы Башкарма комитетының «Административ хокук бозулар турында беркетмәләр төзергә вәкаләтле вазыйфаи затлар хакында» 2016 елның 21 гыйнварындагы 91 карарына түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1.1. Әлеге карарның 1 пунктын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«1. Административ хокук бозулар турында Татарстан Республикасы Кодексының 2.1 (Татарстан Республикасы дәүләт хакимияте органы, башка дәүләт органы, җирле үзидарә органы, предприятие, учреждение, башка оешмаларның исемнәрен һәм башка белешмәләрне элмә тактада күрсәткәндә телләр турында Татарстан Республикасы законнарын бозуга карата), 2.4-2.8, 2.12, 2.13 статьяларында, 2.15, 2.17, 2.19, 2.20, 2.21, 2.22, 3.2-3.8, 3.10 (гражданнарга карата), 3.11, 3.14-3.17, 4.4, 5.1, 5.2, 5.6 (тиешле муниципаль берәмлекләр территорияләрендә гамәлгә ашырыла торган муниципаль ташуга карата) статьяларының 2 өлешендә каралган административ хокук бозулар турында беркетмәләр төзү хокукын, Татарстан Республикасы Алабуга муниципаль районы Башкарма комитетының түбәндәге вазифаи затларына:

- муниципаль контроль бүлеге башлыгына;
- муниципаль контроль бүлегенең баш белгеченә;


ЭЛЕКТРОННЫЙ ТАТАРСТАН

- тәртип саклау буенча җәмәгать пунктларының баш белгеченә;

- тәртип саклау буенча җәмәгать пунктларының әйдәп баручы белгеченә йөкләргә.».

2. Әлеге карар рәсми рәвештә бастырып чыгарылырга тиеш.

3. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны Алабуга муниципаль районы Башкарма комитеты җитәкчесенең инфраструктура үсеше буенча урынбасарына йөкләргә.

Җитәкче

ДОКУМЕНТ ПОДПИСАН ЭЛЕКТРОННОЙ ПОДПИСЬЮ

СВЕДЕНИЯ О СЕРТИФИКАТЕ ЭП

Сертификат: 4DF13A255AE51927759AA463F36F11E0

Владелец: Ахмадеева Эльмира Равильевна

Действителен с 09.01.2025 до 04.04.2026

Э.Р. Әхмәдиева


ЭЛЕКТРОННЫЙ ТАТАРСТАН

Лист согласования к документу № 1437 от 28.08.2025
Инициатор согласования: Каретина К.Д. Главный специалист
Согласование инициировано: 04.09.2025 11:03

**Лист согласования** Тип согласования: **последовательное**

| N° | ФИО | Срок согласования | Результат согласования | Замечания |
|---|---|---|---|---|
| 1 | Ахмадеева Э.Р. | | Подписано<br>04.09.2025 - 12:02 | - |


ЭЛЕКТРОННЫЙ ТАТАРСТАН